# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЮГАРЫ ПӘНӘЧЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

## К А Р А Р

**№186** **12 сентябрь 2020 ел.**

**"Зәй муниципаль районы Югары Пәнәче авыл җирлеге җирле үзидарәсенең үз вәкаләтләрен даими нигездә башкаручы депутатларына, сайланулы вазыйфаи затларына, җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләренә, белгечләргә хезмәт өчен түләү тәртибе һәм шартлары турында нигезләмә хакында" 2018 елның 26 апрелендәге 95 номерлы Зәй муниципаль район Югары Пәнәче авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү турында**

1998 елның 31 июлендәге 145-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Бюджет кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, 2016 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы кодексы, «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләр башлыкларының, муниципаль берәмлекләр башлыклары урынбасарларының, депутатларның,үз вәкаләтләрен даими нигездә башкаручы җирле үзидарәнең сайланулы органнары әгъзаларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең айлык акчалата түләү күләмнәрен һәм муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладларын арттыру турында» 2020 елның 6 августындагы 658 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә, Зәй муниципаль районы Югары Пәнәче авыл җирлеге Уставына таянып, Зәй муниципаль районы Югары Пәнәче авыл җирлеге Советы

## КАРАР ИТТЕ:

1.: "Зәй муниципаль районы Югары Пәнәче авыл җирлеге җирле үзидарәсенең үз вәкаләтләрен даими нигездә башкаручы депутатларына, сайланулы вазыйфаи затларына, җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләренә, белгечләргә хезмәт өчен түләү тәртибе һәм шартлары турында нигезләмә хакында" 2018 елның 26 апрелендәге 95 номерлы Зәй муниципаль район Югары Пәнәче авыл җирлеге Советы карарына (2018

елның 14 маендагы 96 номерлы, 2018 елның 22 ноябрендәге 125 номерлы, 2018 елның 30 ноябрендәге 128 номерлы карарлар нигезендә кертелгән үзгәрешләр һәм өстәмәләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Әлеге карар белән расланган Зәй муниципаль районы Югары Пәнәче авыл җирлеге җирле үзидарәсенең үз вәкаләтләрен даими нигездә башкаручы депутатларына, сайланулы вазыйфаи затларына, җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләренә, белгечләргә хезмәт өчен түләү тәртибе һәм шартлары турында нигезләмәнең 2.2 пунктында «11163 сум» сүзләрен «11498 сум» сүзләренә алмаштырырга;

1.2. Әлеге карар белән расланган “Зәй муниципаль районы Югары Пәнәче авыл җирлеге җирле үзидарәсенең үз вәкаләтләрен даими нигездә башкаручы депутатларына, сайланулы вазыйфаи затларына, җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләренә, белгечләргә хезмәт өчен түләү тәртибе һәм шартлары турында” нигезләмәгә 2 кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Югары Пәнәче авыл җирлеге башлыгына акчалата түләү күләме

| Вазыйфаның исеме | Акчалата түләү күләме (сумнарда) |
|---|---|
| Муниципаль берәмлек башлыгы | 15 759 |

"

1.3. Әлеге карар белән расланган “Зәй муниципаль районы Югары Пәнәче авыл җирлеге җирле үзидарәсенең үз вәкаләтләрен даими нигездә башкаручы депутатларына, сайланулы вазыйфаи затларына, җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләренә, белгечләргә хезмәт өчен түләү тәртибе һәм шартлары турында” нигезләмәнең 2.14 пунктында «11163 сум» сүзләрен «11498 сум» сүзләренә алмаштырырга

2. Карарны Югары Пәнәче авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Зәй муниципаль районы рәсми сайтының "Авыл җирлекләре" бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

3. Карар 2020 елның 1 октябреннән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

**Совет рәисе**
**авыл җирлеге башлыгы** **М.Х.Туктаров**